Ситдыйкова, Ә. Карурманда ап-ак җилләр исә... / Ә. Ситдыйкова // Мәдәни җомга. – 2025. – №13 (4 апрель). – Б. 8.

# Карурманда ап-ак җилләр исә

***Кулына каләм алган һәр кеше билгеле бер мизгелдә газиз халкының, милләтенең язмышы хакында уйлана башлый. Җаны, бәгыре сызлана. Шул сызланулар аңа тынгылык бирми. Тынгысызлык каләменә күчә. Үз халкының үткәненә, бүгенгесенә, киләчәгенә битараф булмаган каләм иясе бердәнбер көнне аң хәтерен, кан хәтерен барларга тотына. Язмыш тарафыннан шагыйрьлеккә хөкем ителгән җан каләменнән тамган утлы сүзләре башкаларның да хәтерен уятканчы сызланырга, янарга дучар була. Берәүләр сүнеп кала, кемнәрдер әдәбият күгендә йолдыз булып кабына***

Татар шигърияте күгендә якты йолдыз булып балкыган Саҗидә Сөләйманова, Лена Шагыйрьҗаннардан соң килгән Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз Миңнуллиналар буыны да инде әдәбиятта үз сүзләрен әйтә торган шагыйрәләр булып үсеп җитте.

Татар хатын-кызларының шигърияте нәфислеге, зәвыклылыгы, сафлыгы, самимилеге белән аерылып тора. Гүзәл затларыбыз шигърияттә рухи-әхлакый проблемаларны гына яктыртып калмыйлар,тирән эчтәлекле фәлсәфи лирик әсәрләр дә иҗат итә. Шундый шагыйрәләребезнең берсе, Актаныш районының бәләкәй генә Әҗмәт дигән авылында 1987 елның 22 мартында туган, Чаллыда яшәп иҗат итүче Лилия Гыйбадуллина башкалардан үзенең үзенчәлекле шигъри авазы белән аерылып тора. Беркемне дә кабатламый торган аерым аһәң, үзгә фикер сөреше булган, һичшиксез талантлы, киләчәге гаять өметле каләм иясе ул. гаять өметле каләм иясе ул.

Юкка гына әле мәктәптә укыган чорында ук аның иҗатына күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташ игътибар итмәгән. Рәдиф абый Лилиянең ихлас, саф, самими хисләргә төрелгән шигырьләрен сорап алып, үзенә дә белдермичә «Мин бәхетне аталган беренче китабын 11 класста укыган вакытында ук бастырып чыгара. Мәктәп укучысы булуга карамастан, Лилиянең инде үзенчәлекле, тирән фикерле шагыйрә икәнлеге сизелә. Шуңа күрә дә олпат әдипләребез аның киләчәгенә якты өметләр баглыйлар, аңа ышаналар. һәм Лилия аларның ышанычларын аклап, әдәбият дөньясында үз урынын булдыру бәхетенә ирешә. Ул чынлап та шул вакытта ук бәхетне күрү, тану сәләтенә ия булганлыгын иҗаты белән раслап яши.

Аның бер-бер артлы дөнья күргән китапларында, вакытлы матбугат битләрендә басылган шигырьләре сан ягыннан түгел, сыйфат ягыннан аерылып тора. 2021 елда Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә үткәрелгән әдәби конкурста «Шигърият», «Поэма» һәм «Повесть» (үсмерләр әдәбияты) номинацияләрендә I урынны яулап, Лилия Гыйбадуллина бөтен татар дөньясын шаккатырды. Ул шигърияттә генә түгел, әдәбият мәйданында төрле жанрларда иҗат итүче, башкаларны да үз артыннан ияртеп баручы затлы каләм иясенә әйләнде.

Лилиянең әле яңа гына «Язучы» нәшриятында басылып чыккан «Дәвамы бар» дигән шигырьләр һәм поэмалар тупланган китабы (мөхәррире - Газинур Морат) кулга килеп кергәә, мин аның шигърият дөньясына кереп чумдым, һәм әлегәчә аннан чыга алмыйм. Аның шигырьләрен укыганда, әйтерсең лә, сискәнеп йокыдан уянасың, җаның сулык-сулык килеп сызлана башлый.






Илең, көнең, милләтең, халкың, үткәнең, бүгенгең, киләчәгең өчен борчылу хисләре кан хәтерен кузгата.

Китап Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулланың «Ахыргача сулык-сулык» дип исемләнгән кереш сүзе белән башланып китә. Затлы, саллы китапка халык шагыйре кереш сүз язарга алынуы ук укучыга күп нәрсә хакында сөйли.

Кереш сүздән соң урын алып, китапны ачып җибәргән «Сызлану» шигырен укуга ук без шагыйрәнең үзе, аның төпле сүзе, фикере, дөньяга, яшәешкә булган карашы белән очрашабыз:

*Сызлан, дөнья,*
*Көн кайрылып табыласы төннәр өчен.*
*Сызлан, дөнья,*
*Төн кабыннан кабынасы көннәр өчен.*
*Төннең көнгә ялгый-ялгый очка очын,*
*Таңнар булып тоташырга җитәр көчең.*
*Сызлан, дөнья!..*

*...Төн карнында яраласы көннәрең бар,*
*Кон тыныннан яраласы өннәрең бар.*
*Сызлан, дөнья.*
*Кара урман кушындагы кара төндә*
*Җырлар булып табыласы моң мәлең бар.*
*Сызлан, сызлан, ахыргача сулык-сулык...*
*Төн суыгы гөл сабагын кочкан таңда,*
*Кояш белән көзгә кырау очрашканда, Җирне үбеп уятырга соңга калма.*
*Сызлан, дөнья! Йолдыз булып, янып-дөрләп,*
*Сагышларның сафлыгыннан сызлан, йөрәк.*
*Көн-төн чиген сызып кына таң туганда,*
*Өметләрнең аклыгыннан сызлан, йөрәк.*
*Сызлан, сызлан!.. Сызланмасаң, син юк, димәк.*

Ркаил Зәйдулла: «Лилия татар шигъриятендә үз дөньясын тудыра. Лилия искиткеч лирик шагыйрә. Кайчакгт а аның поэмалары да лирик бүлекләрдән гыйбарәт сыман. Галәмгә тоташкан мондый шигъриятне патшалар укыса, кешелек әллә нинди глобаль афәтләрдән арыныр иде», - дип бәяли. Бәяләп кенә дә калмый, ул аның нәкъ шулай буласына ышана.

Әле генә дөнья күргән китабында урын алган «Гали Рәхим» һәм «Дәрдемәнд» поэмалары Лилия Гыйбадуллинаның иҗади биеклеген, шигъриятенең үзенчәлеген генә күрсәтеп калмый, ә аның фикер катламын, фәлсәфи җегәрен дә исбатлый сыман. Лилия ерак тарих битенә исемнәрен алтын белән язып калдырган шәхесләребезнең тормышын тирәнтен өйрәнеп, аларның бөеклеген дә, фаҗигале язмышларын да шигъри калыпка салып, укучы күңеленә тоташтыра

Аның ал гып каләменнән тамган шигырь юллары аша гүяки Гали Рәхим, Дәрдемәнд безнең күзләргә бага:

*Адәм гомеренең кадере ни?*
*Ак биләүдән ачып, кәфенгәчә.*
*Фанилыкны кичкән даһиларның*
*һәрбересен дөнья хәтерләсә:*
*Күңеленә, иманына сапса*
*Җиргә туар яңа адәмнәрнең.*
*Карамыйча, барламыйча гына*
*Калтыраган дәвер әләмнәрен.*
*Истә тотса үз бачасын милләт,*
*Тукып торса галәми бер хәтер.*
*Әйтер идем: адәм кадере дә*
*Шәхесенең үз зурлыгы кадәр.*
*Әйтер идем...*
(«Гали Рәхим» поэмасыннан)

Тик ни кызганыч, хәтерсезлек дигән кадерсезлек безнең арттан ияреп йөргән дәвам итә. Кешелек хәтерен уятыр өчен Лилия Гыйбадуллина кебек шагыйрәләр җитми. Адәм гомеренең кадерләрен белер өчен хәтер сакчылары, хәтерне уятучылар кирәк:

*Бер көйдерсен, мең көйдерсен!*
*Мәңге!*
*Гомерләрдер...*
*Гомерләрдер янар өчен.*
*Яна-яна сүнә баруыңны,*
*Сүнә-сүнә януыңны аңлар өчен.*
*Сызылып янсын таңнар булып*
*мәхзүн күңел,*
*Сызлап янсын, янып качсын ялгыз йөрәк.*
*Таңнар булып кабынудан, табылудан*
*Таңнар булып сүнүләрең кадерләрәк...*

Әлеге шигъри юллар белән Лилия Гыйбадуллина «Дәрдемәнд» поэмасын башлап җибәрә. Әйе, гомерләр безгә янар өчен бирелә. Яна-яна сүнә барсак та, таңнар булып сүнүләрнең кадерлерәк икәнен һәрберебездә аңлыйбызмы соң?!. Лилиянең иҗаты белән танышкан укучы әлбәттә бу хакыйкатьме төшенәчәк. Тирән фикерле, сискәндереп милләтебезне гафләт йокысыннан уятучы Лилия Гыйбадуллинаның инсаниятка зур бүләге - «Дәвамы бар» китабы укучылар хозурына юл ала. Татар халкы - мәгърифәтле, укымышлы, китаплы халык булуы белән танылган. Таңнар булып сүнәчәк гомерләребездә китапсыз яшәргә язмасын! Ә без, Лилия үзе вәгъдә иткәнчә, дәвамын көтеп калабыз.

Әлфия СИТДЫЙКОВА